Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге составына керүче Иске Чишмә торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 15 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлегенең Ачы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлеге Иске Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертергә, әлеге сумманың 50% күләмендә 2 төркем инвалидлары, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр түли.
2. Алынган акчаларны Иске Чишмә авылының Садовая, Пионер, Комсомол урамнарындагы юлларын төзекләндерүгә тотарга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.Х. Әхмәтов

Иске Чишмә авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Әхмәтов

«Совет Старошешминского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»